ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОШУГУРОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Советская ул., дом 1, село Старое
Шугурово, Лениногорский район, 423282

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ ШӨГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 1 нче йорт, Иске Шөгер
авылы, Лениногорск районы, 423282

Тел.: (8-85595) 3-45-42, факс: (8-85595) 3-45-43, Sshug.Len@tatar.ru,
leninogorsk.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 28 октябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер җирлегенең Иске Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәт ветераннары, ветераннары һәм хәрби хәрәкәттә катнашучыларның тол калган хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, халык саны 18 яшькә җиткән җирлек халкының гомуми санынннан 30% тан артмаска тиеш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1) Иске Шөгер авылы юлларын карап тоту, юлларга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләү өчен түләү), М. Җәлил, Мурзин, Калинин урамнары буенча;
2)җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган һәм кул белән чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү

буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);

3)тракторчы хезмәтләре өчен түләү (территорияне коры-сарыдан һәм чүп үләненнән чабу, кардан чистарту, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү);

4) Иске Шөгер авыл мәдәният йортының терәк стенасын ремонтлау һәм территорияне киртәләү (чыгым материаллары сатып алу һәм килешү буенча түләү);

5)сәхнә костюмнары сатып алу (чыгым материалын сатып алу, килешү буенча түләү);

6) «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;

7) Җирләү урыннарын карап тоту территориясен төзекләндерү (коры-сары һәм чүп үләннәрен чабу, килешү буенча түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3.Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Шөгер - җирле үзидарә бинасы, Совет урамы, 1 нче йорт, Совет урамы, 3 нче йорт буенча урнашкан балалар бакчасы бинасында, М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М. Шиһапова